Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Чыты авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Чыты авыл җирлеге Башлыгы
КАРАРЫ

5 ноябрь, 2025 ел № 3

Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге уставының 22 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Чыты авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 2019 елның 08 ноябрендәге 153 номерлы Чыты авыл җирлеге Советы карары (2021 елның 13 декабрендәге 35 номерлы карар редакциясендә) нигезендә карар бирәм:

1. Түбәндәге торак пунктларда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Питрәч муниципаль районының Чита авыл җирлегендә гражданнар җыеннарын билгеләргә:

1.2. Чыты авылында. Гражданнар җыенын ике этапта уздырырга:

- гражданнар җыенының беренче этабы 2025 елның 24 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта авыл җирлегенең административ бинасы янында Совет урамы, 126а й. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә түбәндәге урамнарда теркәлгән кешеләрне кертергә: Чулпан, Болын, Газинур, Зур, Күпер урамнары;

- 2025 елның 24 ноябрендә 13 сәгать 30 минутта авыл мәдәният йорты бинасында (Кооператив урамы, 85 йорт) гражданнар җыенының икенче этабы. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Колхоз, Кооператив, Вахитов Мәктәп, Үзәк, Совет урамнарында теркәлгән халыкны кертергә.

«Сез, 2026 елда Чыты торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, 90 яшьтән өлкәнрәк гражданнар, студентлар тыш 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл

итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.2. Иске Йорт авылында. 2025 елның 25 ноябрендә 10.00 сәгатьтә Кооператив урамы, 34 йорт адресы буенча авыл клубы бинасы янында халык җыенын үткәрергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез, 2026 елда Иске Йорт торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, 90 яшьтән өлкәнрәк гражданнар, студентлардан тыш 1650 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- ремонт, коймa кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү;

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Чыты авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Чыты авыл җирлеге башлыгы С.Ә. Фәйзрахманов